**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 153** **10.12.2023 ел**

**2025 елга һәм 2026 - 2027 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ

1 статья

1. 2025 елга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 6183,0 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 6183,0 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты дефицитын 0 мең сум күләмендә.

2. 2026 һәм 2027 елларга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2026 елга 6270,6 мең сум, 2027 елга 6331,6 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2026 елга 6270,6 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 157,8 мең сум һәм 2027 елга 6331,6 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 306,2 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 2026 елга 0 мең сум, 2027 елга 0 мең сум күләмендә.

3. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 2025 елга һәм 2026 - 2027 еллар план чорына финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең 2026 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең 2027 елның 1

гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең 2028 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

3 статья

Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетында 2025 елга, 2026 - 2027 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. 2025 елга һәм 2026 - 2027 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 кушымта нигезендә расларга.

2. 2025 елга һәм 2026 - 2027 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 кушымта нигезендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2025 елга 0 мең сум күләмендә, 2026 елга 0 мең сум күләмендә, 2027 елга 0 мең сум күләмендә расларга.

5 статья

1. Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына юллана торган бюджет ассигнованиеләре күләмен түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга расларга:

- килешүләр нигезендә Александр Бистәсе авыл җирлегендә яшәүчеләрнең ялын оештыру өчен шартлар тудыруга, мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен 2025 елга 3160,6 мең сум, 2026 елга 3160,6 мең сум, 2027 елга 3160,6 мең сум күләмендә.

2. 2025-2027 елларда әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына күчерү ай саен, тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6 статья

Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетында җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Зәй муниципаль районы бюджетыннан алына торган дотацияләрне 2025 елда – 4520,0 мең сум, 2026 елда – 4590,4 мең сум, 2027 елда 4644,3 мең сум күләмендә расларга.

7 статья

Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетында хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Зәй муниципаль районы бюджетыннан алына торган

субвенция күләмен 2025 елда 183,0 мең сум, 2026 елда 200,2 мең сум, 2027 елда 207,3 мең сум күләмендә расларга.

8 статья

1. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2025 елда муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык департаменты территориаль бүлеге, төзелгән килешү нигезендә, Зәй муниципаль районы Александр

Бистәсе авыл җирлегенең бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

10 статья

Муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2025 елда түләнергә тиешле товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмый торган күләмдә Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетының 2024 елның 1 гыйнварына калган акчалары 2025 елда, Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

11 статья

Карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

12 статья

Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **С.А. Кузнецов**